**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
**РЫБНО-СЛОБОДСКОГО**
**ГОРОДСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**
**РЫБНО-СЛОБОДСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**БАЛЫК БИСТӘСЕ**
**МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**БАЛЫК БИСТӘСЕ**
**ШӘҺӘР ҖИРЛЕГЕ**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

ПОСТАНОВЛЕНИЕ                    КАРАР

2024 елның 30 сентябреннән                    Балык Бистәсе штп.                    № 184

Муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законны тормышка ашыру максатларында, «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында» 2010 елның 2 ноябрендәге 880 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарына, шулай ук Башкарма комитетның 2016 елның 21 июнендәге 96пи номерлы “Муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибе турында”гы карарына, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы «Балык Бистәсе шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, КАРАР БИРӘМ:

1. Кушымта итеп бирелә торган түбәндәгеләрне расларга:

1.1. Белешмә (өземтә) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын (кушымта №1);

1.2. Элек хосусыйлаштырылган торак урыннарны муниципаль милеккә кабул итү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын (кушымта №2).

1.3 Муниципаль торак фондында гражданнарга наем шартнамәсе буенча хезмәт урыныннан торак урыннары бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын (кушымта №3).

1.4. Муниципаль милектәге җирләрдә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыруга шартнамә төзү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын (кушымта №4).

2. Үз көчен югалткан дип танырга:

2.1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Балык Бистәсе шәһәр җирлеге Башкарма комитетының 2022 елның 31 мартындагы «Муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында» 29 номерлы карарының 1.7. пункты.

2.2. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Балык Бистәсе шәһәр җирлеге Башкарма комитетының 2022 елның 31 мартындагы «Муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында» 29 номерлы карарының 1.8. пункты.

2.3. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Балык Бистәсе шәһәр җирлеге Башкарма комитетының 2022 елның 27 сентябрендәге “Муниципаль торак фондында гражданнарга наем шартнамәсе буенча хезмәт урыныннан торак урыннары бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында” гы 78 номерлы карары.

2.4. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Балык Бистәсе шәһәр җирлеге Башкарма комитетының 2022 елның 28 октябрендәге “Муниципаль милектәге җирләрдә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыруга шартнамә төзү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында”гы 85 номерлы карары.

2.5. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Балык Бистәсе шәһәр җирлеге Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Балык Бистәсе шәһәр җирлеге Башкарма комитетының 31.03.2022 ел, № 29 карары белән расланган белешмә (өземтә) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында»23.11.2022 ел, №89 карары.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Балык Бистәсе шәһәр җирлегенең түбәндәге адрес буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендында: Балык Бистәсе штп., Ленин ур., 48А йорт һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.

4. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне үземнең җаваплылыкта калдырам.

Җитәкче М.В. Мәгыйзов